

Ләмберәдә яшәvче карт кешеләрнен берсе Касим Садыйк улы Искандяровка туксан биш яшь тулды. Газета битләрендә без ветеран, педагог, яшьләрнен акыллы остазы турында сойләгән идек. Язма героебызнын Юбилей бәйрәме алдыннан Ләмберәнен «Призыв» газетасы хезмәткәрләре Искандяровларнын кунакчыл йортында булалар һәм Касим Садыйк улы һәм анын кызы Клара Касим кызы белән тагын бер кат сойләшеп алалар. Бу юлы Тарасполь авылына кvбрәк игътибар иткәннәр, язма героенын бай рухи доньясы, тормыш кредосы турында язганнар һәм шәхес буларак кvрсәтергә тырышканнар. Шулай ук озак яшәv серләрен ачканнар.      - Остәл артында кон саен унике кеше утыра иде: әти - әнием, әбием Шәрифә апа, дәv әтием, без - жиде бала, тагын бер туганым - әтием Садыйк Айнулла улы тәрбияләгән Нәсрулла, - дип искә ала ветеран. Әтием апасынын ире бик яшьли vлеп китә. Ул шәхси тормышын оештыра алсын очен, апасынын баласын Нәсрулланы vз гаиләсенә алып тәрбияли. Тагы әбиемнен ун конгә бер тапкыр гаиләгә зур икмәк пешергәнен хәтерлим. Әтием бик намуслы, шул ук вакытта оста оештыручы да булды. Грамотасы аз булуына карамастан, табигать ана тапкырлык һәм акыл биргән. Шуна колхоз рәисе итеп сайлаганнар һәм ялгышмаганнар якташларым. Әтием житәкләгән хужалыкта эшләр әйбәт барды.

Безгә, балаларына килгәндә, ул белем бирv очен ботен кочен куйды. Олкән абыем Фатыйх, табиб булырга хыяллана иде. Ул Саранскта фельд-шерлыкка укыган вакытта ук авылдашларын дәвалады; авылдашларыбыз безгә мазь һәм порошок артыннан килеп йоргәннәре исемдә. Шәрифә әбиебезне дә дәвалады Фатыйх абыем. Без барыбыз да анардан оста табиб чыгар дип уйлаган идек, әмма сугыш барлык планнарын челперәмә китерде. Боек Ватан сугышы башлангач, Фатыйх абыем фронтка китте һәм сугышынын беренче коннәрендә vк Шепетовка тирәләрендә һәлак булган хәбәре килде. Без анын кайда кvмелгәнен дә белмибез.

Касим Садыйк улы да белемгә омтыла. Башта Тараспольдагы башлангыч мәктәпне тәмамлый. Анда аны олы жанлы укытучы Габдрахман Давыдов укыткан.

- Менә шул вакытта мин рус телен генә белмәдем, - дип уртаклашуын дәвам итә Касим Садыйк улы. – Дәреслекләребез татар телендә иде һәм укыту да шул ук телдә алып барылды. Рус телен мин Пензятка авылы жиде еллык мәктәбендә укыганда vзләштердем. Әлегә кадәр vземнен укытучым Ксения Николаевна Есаулкованы рәхмәт сvзләре белән искә алам.

Аннары Ләмберә педагогия училищесында укый Касим Садыйк улы Искандяров. Сонынннан ул, унжиде яшендә, vз теләге белән фронтка китә. Конбатыш фронтындагы куркыныч сугыш эченә керә. Смоленск олкәсендәге ут эчендә кем янында кем сугышканын да билгели ала алмый торган каночкеч сугышта да Ватаны очен корәшә ул. Нәкъ шул вакыт аягы каты яралана. Кvп кан югалтып жирдә яткан арада, кинәт берәvнен тавышын ишетә. Ул бергә сугышкан иптәше тавышы була. Жавап бирергә тырышса да, тик ынгырашырга гына коче житә яраланган Касим Садыйк улынын. Озакламый санитарлар да килеп житәргә олгерә. Фронт яны госпиталенә урнаштыралар яралы якташыбызны. Табиб Касим Садыковичны карагач, кулын селтәп: «Аягынны ампутацияләргә һәм бернинди киреләнv булмасын! Югыйсә гангрена башланачак!» Әмма ул, унсигез яшьлек малай, аягын кисәргә бирми: «Нәрсә булганы - булыр! Язмыштан узмыш юк!» Һәм нинди дер могжиза туа шул вакыт; аягын саклап кала алалар. Берничә айдан янә фронтка китә, янә ут эченә эләгә. Кvпне кvрә Совет солдаты: Туган иле, туган туфрагы очен дошман белән сугыша, фашистлар танкын яндыра…һәм бvләкләvләр, мәсәлән, «Батырлык очен» медале...
Сугыштан сон К.С.Искандяров vзенен кече Ватанына әйләнеп кайта. Педагогия институтында укый, аннан мәктәптә укытучы булып эшли. Комсомол райкомынын беренче секретаре итеп жибәрелгәч, Ләмбердә vзенен булачак хатыны Алия Хикмәтулла кызы белән таныша. Алия Хикмәтулловна шул вакыт башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли торган була. 1948нче елда алар ойләнешәләр. Башта Алиянен әти-әнисе янында, аннан сон фатирда яшиләр. Тик һәрвакыт vз йортлары турында хыялланалар. Тозелеш очен барысын да әзерли башлыйлар, әмма... Менә шунда Касим Садыйковичнын ин яхшы кеше сыйфатлары, анын игелеклелегенен тирәнлеге тулы чагылыш тапкан. Үз оч баласыннан тыш, Касим Садыкович хатыны белән бертуганын тәрбияләгәннәр. Шул балага яна сафка бастыра башлаган йортын бирә. Егет шәхси тормышын оештыра алсын дип биргән, ә Касим Садыкович vзе, гаиләсе белән, фатирда калган.
Һәм тагын гомуми портретына берничә штрих остәп язабыз. Касим Садыйк улы хайваннарны бик ярата икән. Балачакта Тарасполендә «Чегән» исемле яраткан эте булган. Сонрак, Ләмберәдә яшәгәндә, торле токым этләр дә асраган, аучылык белән дә мавыккан.
- Дорес, әмма сәер, - ди Клара Касим кызы елмаеп. – Әтиебез мылтык алып, ау этен янында ияртеп ауга китәргә китә иде, ләкин бер тапкыр булса да куян яки vрдәк алып кайтканнары булмады. Бер тапкыр да! Ул урманда табигать белән соклана, ял итә икән, ә хайваннарга яки кошларга бер тапкыр да атмавы сонга таба ачыкланды.
Әнгәмә ахырында корреспондентлар тагын бер сорауга живапны ишетәләр.
- Озын гомернен сере нәрсәдә? - Касим Садыкович бер минутка уйланып китә, аннары жавап бирә. - Минемчә, бу минем беркайчан да чvп-чар белән корәшмәгәнлектән, кешеләрне хормәт итәргә тырышканымнан; дусларым кvп булды, ә менә кемгә дә булса конләшv булмады. Конләшv, усаллык кешене эчтән яндыра. Тагы тәмәке тартмадым. Беренче тапкыр сугышка кергәч кенә тарттым, тыныч тормыш башлангач ук ташладым. Тынычлык, игелеклелектән дә кvп нәрсә тора. Остәвенә, мин сонгы вакытка булдыра алган кадәр хәрәкәттә булырга тырыштым, кvп йордем, иртәм зарядкадан башладым. Баналь әйберләр диярсез, әмма болар барысы да озын гомерлелектә зур роль уйный. Яше булуга карамастан, Касим Садыйк улы әлегә кадәр укырга ярата. Оендә яхшы китапханәсе бар, ә газеталар уку – анын очен кон таләбе. Һәм, әлбәттә, телевидение

буенча яналыклар блокларын караштыра. Шулай ук, яраткан хатынына багышлап, элек кыска шигырьләр язган. Кондәлек тә алып барган. Гаилә очен авыр сынаулар барган коннәрдә: әти - әнисе вафат булгач, хатыны, бертуганынын ире фажигале тостә вафат булгач, кvнелендәге авырлыклар язган юллар белән таралыр, хәле жинеләеп китәр дип тә язган. Касим Садыйк улы кондәлеккә (йорәгенә авыр чаклар туры килгәч, юллардагы сvзләр хәле белән уртаклашыр кебек булса да)  язган. Язуларны ул рус телендә генә алып барган, татар телендә дә бик тә грамоталы яза ала. Әтиеннән белемгә амтылуны кызы Клара Касимовна да алган. Коръәнне яттан белә торган туганнан туган сенеленен улы ярдәме белән ул гарәп телен ойрәнә. Касим Садыйковичнын ике улы да югары белем алганнар.
Бvген аларнын йорты элеккегечә туган-тумачалары һәм якыннары очен ачык; бәйрәмнәрдә һәм ял коннәрендә бу йортка кvп кеше жыела.

**Наилә Насырова**